ГЛАВА ЧУКМАРЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАС
САРМАН МУНИЦИПА
РАЙОНЫ ЧУКМАРЛЫ АВЫ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 ел, 8 ноябрь Чукмарлы авылы № 3

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Чукмарлы авылы гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Чукмарлы авылы гражданнары җыенын Чукмарлы авылы мәдәният йорты бинасында 2021 елның 15 ноябренә 09 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, ялгыз өлкән кешеләр, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Чукмарлы авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2022 елда үзара салымны 400 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

- Зират территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү, Чукмарлы авылы зираты ое өчен төзелеш материаллары сатып алу;

- Чукмарлы авылы урамнарны яктырту объектларын  карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар,энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

- Чукмарлы авылында мәдәни чаралар уздыру өчен бүләкләр алу (Сабантуй, өлкәннәр көне, 9 Май);

-Беларусь 82.1» тракторы өчен  КУН-10 төягече сатып алу;

-« Чукмарлы  авылында «Беларусь 82.1» тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү);

-Бензин чапкычлары өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу

ӘЙЕ ЮК?».

3. Гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны Чукмарлы авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

4. Әлеге карарны «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Чукмарлы авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

5. Әлеге карар  игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Чукмарлы
авыл җирлеге башлыгы: И.Х.Хадиуллин